ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш); № 48 (I өлеш); № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «хуҗалык» сүзен «икътисадый (хуҗалык)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:
а) 1 өлештә:
түбәндәге эчтәлекле яңа утыз тугызынчы һәм кырыгынчы абзацлар өстәргә:
«каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар ясау максатларында каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын билгеләү, каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар ясау максатларында региональ оператор һәм (яисә) каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтен кулланучы тарафыннан каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын сайлау тәртибен раслау;
әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау;»;
түбәндәге эчтәлекле кырык беренче абзац өстәргә:
«әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру;»;

утыз тугызынчы абзацны кырык икенче абзац дип санарга һәм анда «әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыру» сүзләрен «әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру» сүзләренә алмаштырырга;

кырыгынчы абзацны кырык өченче абзац дип санарга;

б) 2 өлештә «кырыгынчы» сүзен «кырык өченче» сүзләренә алмаштырырга;

3) 96 статьяның 1 өлешендә «башка эшләр» сүзләреннән соң «су турындагы законнар,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 16 ноябрь
№ 112-ТРЗ